ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1617 «_07_»____12______2016 ел

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының опека
һәм попечительлек өлкәсендә
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирергә:

2. 2.5 пунктның 2 нче баганасы, б пунктчасында:

«соңгы 12 айда вазыйфасын һәм уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен – керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгы күчермәләре, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнан белешмә) " графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2.5. б) «соңгы 12 айдагы вазыйфасын һәм уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен- керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгы күчермәләре)»;

2.6 пункттa., 2 багана, «ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан таләп ителергә мөмкин булган документлар " графасында:
яшәү урыныннан йорт (фатир арасы) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын йә торак урынга милек хокукын раслый торган башка документ, һәм яшәү урыныннан финанс лицевой счеты күчермәсе;
опекун булырга теләк белдергән гражданның гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителмәвен раслый торган эчке эшләр органнары белешмәсе;
мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты;
торак урыннарның санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән белешмәләргә (опека һәм попечительлек органы белгеченең гарызнамәсе буенча, торак урынга керү мөмкинлеген мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп)» ахырында түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:
«– соңгы 12 айдагы вазыйфасын һәм уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен- керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгы күчермәләре)»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Контроль Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. П. Смирновага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы И.М. Дәрҗеманов